КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 7 сентябрь г.Казань № 798

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) һәм социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы объектларының һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итүчеләр күрсәткән хезмәт күрсәтүләрнең инвалидлар өчен уңайлы булуын тәэмин итүдә төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруны оештыру тәртибен раслау турында» 2014 ел, 25 ноябрь, 909 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) һәм социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы объектларының һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итүчеләр күрсәткән хезмәт күрсәтүләрнең инвалидлар өчен уңайлы булуын тәэмин итүдә төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруны оештыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) һәм социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы объектларының һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итүчеләр күрсәткән хезмәт күрсәтүләрнең инвалидлар өчен уңайлы булуын тәэмин итүдә төбәк дәүләт

тикшерүен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруны оештыру тәртибен раслау турында» 2014 ел, 25 ноябрь, 909 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 28 декабрь, 1067 нче; 2018 ел, 22 август, 677 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) һәм социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы объектларының һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итүчеләр күрсәткән хезмәт күрсәтүләрнең инвалидлар өчен уңайлы булуын тәэмин итүдә төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруны оештыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.4 нче пунктта татар текстында «гамәлгә ашырыла» сүзләре алдына «, шул исәптән риск-юнәлешле алымны кулланып» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 2.12 – 2.22 нче пунктлар өстәргә:

«2.12. Төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда риск-юнәлешле алымны куллану максатларында, социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләрнең эшчәнлеге Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт тикшерүенең (күзәтчелегенең) аерым төрләрен оештырганда риск-юнәлешле алымны куллану һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 17 августындагы 806 номерлы карары белән расланган Юридик затларның һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең эшчәнлеген һәм (яки) алар куллана торган җитештерү объектларын билгеле бер риск категориясенә яки куркынычның билгеле бер классына (категориясенә) кертү кагыйдәләре нигезендә рискның аерым категориясенә кертелергә тиеш.

Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр эшчәнлеген рискның аерым категорияләренә кертү бу Тәртипкә теркәлгән кушымта нигезендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр эшчәнлеген рискның аерым категорияләренә кертү критерийлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.13. Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр эшчәнлеген риск категорияләренә кертү турында карар һәм риск категориясен үзгәртү турында карар вәкаләтле органның боерыгы белән рәсмиләштерелә.

Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче эшчәнлеген рискның аерым категориясенә кертү турында карар булмаганда, социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче эшчәнлеге рискның түбән категориясенә кертелгән дип санала.

2.14. Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләрне план буенча тикшерүләр үткәрү вакыты социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче эшчәнлеген рискның аерым категориясенә кертүне исәпкә алып билгеләнә.

Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләргә карата план буенча тикшерүләр рискның бирелгән категориясенә карап үткәрү түбәндәге вакыт аралыгында башкарыла:

югары рисктагы категория өчен – ике елга бер тапкыр;

шактый рисктагы категория өчен – өч елга бер тапкыр;

урта рисктагы категория өчен – дүрт елга бер тапкырдан артмаган һәм биш елга кимендә бер тапкыр;

уртача рисктагы категория өчен – алты елга бер тапкырдан артмаган һәм сигез елга кимендә бер тапкыр;

Түбән рисктагы категориягә кертелгән социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләргә карата план буенча тикшерүләр үткәрелми.

2.15. Вәкаләтле орган эшчәнлегенә риск категорияләре бирелгән социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр исемлеген (алга таба – исемлек) электрон формада һәм кәгазьдә алып бара.

Исемлек түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүченең тулы исеме (фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булганда);

төп дәүләт теркәү номеры;

салым түләүченең индивидуаль номеры;

социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүченең урнашу (эшчәнлек алып бару) урыны;

социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчене риск категориясенә кертү турында боерыкның реквизитлары (датасы һәм номеры), риск категориясенә күрсәтмә, шулай ук социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче эшчәнлеген риск категориясенә кертү турында карар кабул итү өчен нигез булган мәгълүматлар.

2.16. Исемлеккә кертелгән социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче эшчәнлеген риск категориясенә кертү турындагы карар нигезендә югары һәм шактый риск категориясенә кертелгән социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр турында мәгълүмат вәкаләтле органның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла һәм актуаль хәлдә тотыла.

Әлеге мәгълүматны урнаштыру Россия Федерациясенең дәүләт серен саклау турындагы законнары таләпләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

2.17. Эшчәнлеге риск категорияләренең берсенә кертелгән социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче соравы буенча вәкаләтле орган мондый сорау кергән көннән 15 эш көненнән дә артмаган вакытта аңа аларның эшчәнлеген риск категориясенә кертү турында мәгълүмат, шулай ук аның эшчәнлеген рискның аерым категориясенә керткәндә файдаланылган белешмәләр бирә.

2.18. Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче вәкаләтле органга аның эшчәнлегенә карарта элек бирелгән дәүләт контроле (күзәтчелеге) риск категориясен үзгәртү турында гариза (алга таба – гариза) бирергә хокуклы.

Гаризада түбәндәге мәгълүматлар бирелә:

юридик затның тулы исеме, индивидуаль эшмәкәрнең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булганда) ;

төп дәүләт теркәү номеры;

салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры;

социаль хезмәтләр күрсәтү объектының (объектларының) урнашу урыны;

социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче эшчәнлегенә элек бирелгән риск категориясе турында мәгълүмат;

юридик затның адресы, индивидуаль эшмәкәрнең яшәү урыны адресы (кирәк булганда элемтә өчен башка почта адресы), телефоны һәм электрон почта адресы (булганда).

2.19. Гаризага социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче эшчәнлегенең дәүләт контроле (күзәтчелеге) объектларын гариза бирүче бирү өчен дәгъва итә

торган рискның аерым категориясенә кертү критерийларына туры килүе турында документлар теркәлә.

2.20. Вәкаләтле орган гаризаны карап тикшерә, социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче тарафыннан тапшырылган һәм аның карамагында булган документларны бәяли һәм аларны карап тикшерү йомгаклары буенча мондый гаризаны алган көннән 15 эш көненнән дә артмаган вакытта түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

гаризаны канәгатьләндерү һәм риск категориясен үзгәртү;

гаризаны канәгатьләндерүдән баш тарту.

2.21. Вәкаләтле орган бу Тәртипнең 2.20 нче пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән өч эш көне эчендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчегә кабул ителгән карар турында гаризада күрсәтелгән почта адресы буенча яки вәкаләтле вазыйфаи затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә, социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүченең электрон почтасы адресы буенча (әгәр дә мондый адрес шул ук эзлеклелектә Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, Индивидуаль эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрында булса йә алар тарафыннан вәкаләтле органга элегрәк тапшырылган булса) тиешле хәбәрнамә җибәрү юлы белән хәбәр ителә.

Гаризаны канәгатьләндерүдән баш тарту турында карар кабул ителгәндә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчегә баш тартуның сәбәпләре турында хәбәр ителергә тиеш.

Вәкаләтле орган тарафыннан кабул ителгән гаризаны канәгатьләндерүдән баш тарту турындагы карар белән килешмәгән очракта, социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче мондый карарга карата административ һәм (яки) суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.»;

әлеге Тәртипкә кушымта (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) һәм социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы объектларының һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәткән хезмәт күрсәтүләрнең инвалидлар өчен уңайлы булуын тәэмин итүдә төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруны оештыру тәртибенә кушымта

Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) һәм социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы объектларының һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәткән хезмәт күрсәтүләрнең инвалидлар өчен уңайлы булуын тәэмин итүдә төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче эшчәнлеген рискның аерым категорияләренә кертү
критерийлары

1. Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) һәм социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы объектларының һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәткән хезмәт күрсәтүләрнең инвалидлар өчен уңайлы булуын тәэмин итүдә төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда, социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр эшчәнлеген рискның аерым категориясенә кертү социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан мәҗбүри таләпләрне мөмкин булган үтәмәүнең потенциаль тискәре нәтиҗәләре авырлыгы критерийлары нигезендә һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәмәү ихтималы критерийларын исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

2. Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр, социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучылар гомеренә һәм һәм сәламәтлегенә зыян китерүнең потенциаль рискы күрсәткеченнән чыгып, түбәндәге риск категорияләренә керә:

сәламәтлеккә зыян китерүнең потенциаль рискы күрсәткече 2дән күбрәк тәшкил итә – югары риск;

сәламәтлеккә зыян китерүнең потенциаль рискы күрсәткече 0,7дән 2гә кадәр тәшкил итә – шактый риск;

сәламәтлеккә зыян китерүнең потенциаль рискы күрсәткече 0,4тән 0,7гә кадәр тәшкил итә – урта риск;

сәламәтлеккә зыян китерүнең потенциаль рискы күрсәткече 0,2дән 0,4кә кадәр тәшкил итә – уртача риск;

сәламәтлеккә зыян китерүнең потенциаль рискы күрсәткече 0,2дән кимрәк тәшкил итә – түбән риск.

3. Социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның гомеренә һәм сәламәтлегенә зыян китерүнең потенциаль рискы күрсәткече (R) социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәмәү мөмкин булган потенциаль тискәре нәтиҗәләрнең авырлыгын һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәмәү ихтималын исәпкә ала һәм түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$R = G \times P,$$

монда:

G – социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәмәү мөмкин булган потенциаль тискәре нәтиҗәләрнең авырлыгы күрсәткече;

P – социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашырганда социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәмәү ихтималы күрсәткече.

4. Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәмәү ихтималы булган потенциаль тискәре нәтиҗәләрнең авырлыгы күрсәткече, бер мең кешегә мәҗбүри таләпләрне үтәмәү мөмкинлеге барлыкка килүнең мөмкин булган ешлыгын һәм потенциаль тискәре зыяннары таралу масштабын исәпкә алып түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$G = U \times \frac{M}{1000},$$

монда:

U – социаль хезмәт күрсәтү формалары буенча социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүченең[1] егәрлегенә карап билгеләнә торган мәҗбүри таләпләрне үтәмәү мөмкинлегенең потенциаль тискәре зыяннары барлыкка килү ешлыгы;

M – социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның социаль хезмәт күрсәтү фоормалары буенча категорияләре санына карап билгеләнә торган мәҗбүри таләпләрне үтәмәү мөмкинлегенең потенциаль тискәре зыяннары таралу масштабы.

5. Мәҗбүри таләпләрне үтәмәү мөмкин булган потенциаль тискәре зыяннарның барлыкка килү ешлыгы күрсәткеченең мәгънәсе вәкаләтле орган карамагында булган социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче егәрлеге турындагы мәгълүматлар буенча билгеләнә.

6. Мәҗбүри таләпләрне үтәмәү мөмкинлеге булган потенциаль тискәре зыяннар таралу масштабы күрсәткеченең мәгънәсе 1 нче таблица нигезендә билгеләнә.

---

[1] Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче егәрлеге – бәяләүне үткәргән ел алдыннан килгән ел дәвамында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтелгән социаль хезмәт күрсәтүләрдән потенциаль файдаланучылар саны.

1 нче таблица

| Социаль хезмәт күрсәтү формалары буенча социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр | Мәҗбүри таләпләрне үтәмәү мөмкин булган потенциаль тискәре зыяннар таралу масштабы күрсәткече |
|---|---|
| Стационар формада социаль хезмәтләр күрсәтүче социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр | 5 |
| Стационар һәм ярымстационар формада социаль хезмәтләр, шулай ук хезмәтләр өйдә хезмәтләр күрсәтүче социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр | 2,5 |
| Стационар һәм ярымстационар формада социаль хезмәтләр күрсәтүче социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр | 2 |
| Ярымстационар формада социаль хезмәтләр күрсәтүче социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр | 1 |
| Ярымстационар формада социаль хезмәтләр, шулай ук өйдә хезмәтләр күрсәтүче социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр | 0,5 |
| Өйдә социаль хезмәтләр күрсәтүче социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр | 0,2 |

7. Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашырганда социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәмәү ихтималы күрсәткеченең мәгънәсе, вәкаләтле орган карамагында булган мәгълүматны (риск категориясенә кертү датасына) исәпкә алып, 2 нче таблица нигезендә билгеләнә.

2 нче таблица

| Мәгълүматның эчтәлеге | Күрсәткеч-нең мәгънәсе |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Соңгы өч ел эчендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчене риск категориясенә кертү турында карар кабул итү датасына законлы көченә кергән санитария-эпидемиология нормаларын һәм кагыйдәләрен, медицина эшчәнлеген гамәлгә ашырганда лицензия таләпләрен, янгын куркынычсызлыгы таләпләрен, социаль, инженер | 3 |

| 1 | 2 |
|---|---|
| һәм транспорт инфраструктурасы объектларының һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәткән хезмәт күрсәтүләрнең инвалидлар өчен уңайлы булуын тәэмин итүне бозган өчен административ җәза билгеләү турында карарлар булу | |
| Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүченең соңгы өч ел эчендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчене риск категориясенә кертү турында карар кабул итү датасына вакытында үтәлмәгән Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү һәм социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы объектларының һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәткән хезмәт күрсәтүләрнең инвалидлар өчен уңайлы булуын тәэмин итүгә дәүләт тикшерүе (күзәтчелеге) өлкәсендә, шулай ук санитария-эпидемиология нормаларын һәм кагыйдәләрен, медицина эшчәнлеген гамәлгә ашырганда лицензия таләпләрен, янгын куркынычсызлыгы таләпләрен бозуларны бетерү турында күрсәтмәләре булу | 2 |
| Соңгы өч ел эчендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчене риск категориясенә кертү турында карар кабул итү датасына законлы көченә кергән санитария-эпидемиология нормаларын һәм кагыйдәләрен, медицина эшчәнлеген гамәлгә ашырганда лицензия таләпләрен, янгын куркынычсызлыгы таләпләрен, социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы объектларының һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәткән хезмәт күрсәтүләрнең инвалидлар өчен уңайлы булуын тәэмин итүне бозган өчен административ җәза билгеләү турында карарлар булмау | 1 |
| Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүченең соңгы өч ел эчендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчене риск категориясенә кертү турында карар кабул итү датасына вакытында үтәлмәгән Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү һәм социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы объектларының һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәткән хезмәт күрсәтүләрнең инвалидлар өчен уңайлы булуын тәэмин итүгә дәүләт тикшерүе (күзәтчелеге) өлкәсендә, шулай ук санитария-эпидемиология нормаларын һәм кагыйдәләрен, медицина эшчәнлеген гамәлгә ашырганда лицензия таләпләрен, янгын куркынычсызлыгы таләпләрен бозуларны бетерү турында күрсәтмәләре булмау | 1 |

Искәрмә. Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә эшчәнлек гамәлгә ашырганда социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәмәү ихтималының берничә күрсәткече булганда күрсәткечләрнең мәгънәләре кушыла.